**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 август № 628

г. Казань

2015/2016 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында

2015/2016 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2015 елның 15 сентябренә кадәр гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын 2015/2016 елның кышкы чорына әзерлек чаралары комплексын эшләүне оештырырга;

2015 елның 1 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка мәнфәгатьле органнары белән берлектә «Буран» оператив планына төзәтүләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының кар көртләре, автомобиль фаҗигалары нәтиҗәсендә аерылып калган затларга үз вакытында медицина ярдәме күрсәтү буенча гамәлләргә әзер булуын тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тәкъдим итәргә:

2015 елның 1 ноябренә кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту буенча муниципаль шартнамәләр төзергә;

юл-коммуналь хезмәтләрнең кышкы шартларда эшләвенә әзерлекне оештырырга һәм шәһәр һәм районнарның тереклек эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле урам-юл челтәрен карап тотуны тәэмин итәргә;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив планнарга төзәтмәләр кертү үткәрергә;

сәүдә һәм җәмәгать тукллануы предприятиеләре җитәкчеләре белән берлектә 2015/2016 елның кышкы чорында куркыныч метеорологик күренешләр килеп туганда уртак кулланылыштагы автомобиль юлларында калган затларны кайнар аш һәм азык-төлек белән тәэмин итү бурычы йөкләнгән предприятиеләрне билгеләргә.

4. Тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитны мониторинглау идарәсенә 2015/2016 елның кышкы чорында табигый гидрометеорологик күренешләр һәм атмосфера процесслары үсеше фаразлары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына үз вакытында тапшырырга;

Казан гарнизоны җитәкчесенә законнар нигезендә республика территориясендә «Буран» планын керткәндә Татарстан Республикасы территориясе буенча үтүче автомобиль юлларында кар көртләрен чистарту һәм кар тоткарлыгында калган кешеләрнең тормышын коткару өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби уку йортлары һәм гаскәри частьләренең шәхси составын, махсус һәм автомобиль техникасын бүлеп бирүне күздә тотарга;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт юл хәрәкәте иминлеге инспекциясе идарәсенә автомобиль юлларын карап тотуны тормышка ашыручы оешмаларга, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы бүлекчәләренә кар көртләре барлыкка килгән урыннарга юл һәм махсус техника хәрәкәтенә, шулай ук кешеләрнең зур төркемнәрен, шул исәптән балаларны алып баручы автомобиль колонналарын һәм җәмәгать тукллануы һәм сәүдәсенең хәрәкәтчән формированиеләрен, вакытлыча транспорт тупланган урыннарга зыян күрүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүче төркемнәрне үткәрүне оештыруга булышлык күрсәтергә;

автомобиль юлларын карап тотуны гамәлгә ашыручы предприятиеләргә автомобиль юлларын кардан чистарту һәм бозлавыкка каршы тору өчен кар чистарту техникасын бүлеп бирүгә шартнамәләр төзергә;

«Россия тимер юллары» ААҖ филиалы – Горький тимер юлының Казан төбәгенә һәм «Россия тимер юллары» ААҖ филиалы – Куйбышев тимер юлына Татарстан Республикасы территориясе аша үтүче тимер юлларда кар көртләрен чистарту өчен эшчеләр һәм техника бүлеп бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән шартнамәләр төзергә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«2006/2007 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2006 ел, 06 октябрь, 503 нче;

«2007/2008 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2007 ел, 17 сентябрь, 473 нче;

«2008/2009 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2008 ел, 25 июль, 533 нче;

«2009/2010 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2009 ел, 6 июль, 456 нчы;

«2010/2011 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2010 ел, 16 сентябрь, 742нче;

«2011/2012 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2011 ел, 4 октябрь, 828 нче;

«2012/2013 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2012 ел, 24 октябрь, 904 нче;

«2013/2014 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 2014 ел, 5 сентябрь, 645 нче».

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков